## Вакыт бушка узмасын

# Ни чәчсәң - шуны урырсың



Ир балалар төркеме үзләренең остазлары белән

**Балачак — кеше тормышының иң бәхетле, серле мизгеле. Балалары шул чорны гомерләре буена хәтер сандыкларында кадерләп сакласыннар өчен өлкәннәр аларның җәйге ялларын оештыру белән ел әйләнәсендә мәшгуль булдылар.**

Менә быел да Кинель-Черкассы авылы табигатенең иң матур почмагында урнашкан «Колос» санаториенда мөселман балалары өчен җәйге смена оештырылды. Биредә Самара өлкәсенең төрле төбәкләреннән җыелган малайлар, кызлар ял итте.

Башка еллардан аермалы буларак, быелгы лагерь тормышы тагын да эчтәлекле иде. Өч атна дәвамында укучылар Ислам дине нигезләрен үзләштерделәр, татар телен өйрәнделәр. Чиста Кинель елгасында су керү, күчмә цирк тамашаларын карау, төрле чараларда актив катнашу, яшьтәшләре белән үзара дуслык хисләрен урнаштыру мизгелләре алар күңелендә якты хатирә булып озак сакланыр әле.

Биредә мөселман балалары догалар һәм намаз уку тәртибен тырышып үзләштерделәр. **Башларына яулык бәйләгән, озын матур күлмәкле кызларга, түбәтәйле малайларга карап, анда яшәүче украин, рус һәм аларның тәрбиялелегенә халыклары таң калдылар.**

Ата-аналар да, үз чиратларында, балаларына шундый истәлекле ял оештырганнары өчен «Колос» лагере администрациясенә, аеруча зур игътибар белән һәм аталарча кайгырту күрсәткән Дамир әфәнде Ходовка, укучыларны Кинель-Черкассы мәчетендә җомга намазын уку бәхетенә ирештергән Марат хаҗи Ходовка бик рәхмәтлеләр.

Даими рәвештә балалар янында булып, укыту-тәрбия эшләрен оештыруны быел Сәйфетдин хәзрәт Мөрсәлимов һәм Радик хәзрәт Газизов үз өсләренә алганнар һәм моны намус белән, оста итеп башкарып та чыктылар. Аларга Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтләре насыйп булсын иде!

Кызыклы уенны хәтерләткән татар теле дәресләрендә балаларга бик күп файдалы мәгълүмат бирделәр. Безнең телебезнең әби-бабайларыбыздан калган бай мирас икәнлеген балалар яхшы аңладылар кебек.

Юкка гына халкыбызның мәкальләре «Тел яшәсә - ил яшәр», «Теле барның - иле бар», дип яңгырамыйдыр инде. Тел - ул милләтнең, илнең нигезе.

Гарәп теле, Ислам дине нигезләрен кызларга Сафия ханым, Асия ханым, Гөлия ханым Газизова, ә малайларга Самара шәһәренең «Нур» мәдрәсәсе шәкертләре һәм хәзрәтләр укыттылар.

Лагерь тормышын җанландырган



Жюри әгъзалары карар кабул итәләр

чараларның берсе Сабантуй бәйрәме булды. Кояшлы көнне Самара шәһәреннән бер төркем егетләр-кызлар десанты санаторий мәйданына килеп төште. Гөрләп Сабантуй башланды. Өлкәбез мөфтие Талип хәзрәт Яруллинның чын күңелдән әйтелгән котлау сүзләре, балалар белән бергә төрле ярышларда катнашуы күңелләребезгә шатлык өстәде.

Чүлмәк вату дисеңме, капчык киеп йөгерү дисеңме, көянтәгә аскан чиләкләр белән су ташу, аркан тарту, кул көрәштерү һәм башка мавыктыргыч уеннарда бөтен лагерь балалары катнашып, төрле призлар яуладылар.

Һәрберебез биредә тәмле пылау белән сыйланды, яңа уңыштан яшелчәләр дә авыз иттек.

Узган дәресләрнең нәтиҗәләрен тикшерү максаты белән татар теле һәм Ислам дине буенча бәйгеләр үткәрелде. «Без татар телен өйрәнәбез» конкурсын оештырган Гөлфия Глушкова, Рәхимә Хейрова һәм Галия Тупасова эчтәлекле чыгышлар һәм презентация әзерләгәннәр иде. Балаларны ике төркемгә бүлеп оештырылган ярыш кискен барды, Бәйгене хөкем итүчеләр - хәзрәтләр һәм «Азатлык» радиосы журналисты милли җанлы Шамил әфәнде Баһаутдин иде. Татар халкының матур гадәтен бозмыйча, Шамил әфәнде бүләкләрен дә алып килгән. Ул эшкуар Гомәр Батыршин җибәргән күчтәнәчләрне дә җиткергән. Балаларның ничек шатлануын күрсәгез икән!

Ислам дине буенча үткән бәйгегә эшмәкәр Габделбәр Савганов шулай ук мул итеп бүләкләр әзерләгән. Ә мөфтиебез җиңүчеләргә дипломнар һәм Рәхмәт хатлары тапшырды. Гомумән, быел бер бала да игътибардан читтә калмады. Викторинада балаларга тапшырылган бөтен бүләкләр дә Самара өлкәсе Диния Нәзарәте, Гомәр әфәнде Батыршин һәм Габделбәр әфәнде Сафганов биргән акчаларга алындылар. Бәйге ахырында һәрбер ял итүчегә истәлеккә радиоприемник тапшырылды. Бәйгедә катнашучы ёлар ярышны моңлы азан тавышы белән башлап җибәрделәр, аннан соң матур итеп Коръән сүрәләрен уку дәвам итте. Балалар Ислам дине тарихы буенча үзләренең белемнәрен күрсәттеләр. Төрле догаларны дөрес, сәнгатьле итеп уку җиңелдән түгел иде, билгеле. Чөнки гадел хөкемдарлар - Самара өлкәсе мөфтие Талип хәзрәт Яруллин белән килгән мөхтәрәм дин кардәшләребез каршында чыгыш ясау - ул үзе бер сынау бит. Ахырда аларның тырышлыгы, белемгә омтылулары жюри әгъзалары тарафыннан югары бәяләнде. Чара бергәләп фоторәсемгә төшү белән тәгәлләнде.

**Киләчәккә оештыру комитетына берәр киңәш биреп үтәсе килә. Мөселман лагерының максатын, нинди эшләр белән шөгыльләнүен әти-әниләргә аңлатып, балалар белән әңгәмә үткәреп, теләкләре булганнарны сайлап алсак, бу хезмәт тагын да отышлырак булыр иде.**

**Балалар фикере буенча, быел оештырылган ял бик күңелле булды. Алар үз вакытларын әрәм итмичә, зур тырышлык белән яңа белем тупладылар. Бу матур эш дәвамлы булып, уңай нәтиҗәләргә китерсен иде. Тәүфыйклы, белемле, үз сүзендә тора торган, тырыш, булдыклы, телен, илен сөюче, Ислам дине буенча яшәүче, әти-әнисе, туганнарының кадерен белүче балалар тәрбияләсәк, тормышыбыз тыныч, матур һәм шатлыклы булыр, иншаллах.**

***Гөлфия ХОДОВА,***
***Кинель-Черкассы авылы.***

Игътибар!
«Ислам-Нур» газетасына язылу дәвам итә.

**Аңа Самара өлкәсенең һәр почта бүлегендә язылырга мөмкин.**

Индекс: 52381

